**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**2018 елның 14 декабре**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 268**

**Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең мәдәният бүлеге»нә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы юстиция министры Заһидуллин Р.И. 2018 елның 01 июнендәге 10-06/8579 номерлы йөкләмәсен үтәү өчен, җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешмаларда (учреждениеләрдә) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары (2018 елның 28 мартындагы 208 номерлы карар редакциясендә) белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең мәдәният бүлеге турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.4 пунктының 2.4.1 пунктчасын 2.4. 2-нче бүлегендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Үз эшчәнлеге предметы буенча муниципаль программаларны эшләүдә катнаша, үз компетенциясе чикләрендә Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программаларын эшләүдә катнаша;».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 6.1 бүлек өстәргә:

«6.1. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу

«6.1.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә бүлек эшчесенең шәхси кызыксынучанлыгы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин һәм шул ук вакытта бүлек хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм аның эшчесе булган бүлекнең законлы мәнфәгатьләре һәм хокуклары арасында каршылыклар килеп чыгарга мөмкин булган һәм бүлекнең мөлкәтенә һәм эш

абруена зыян китерергә сәләтле вәзгыять аңлашыла.

6.1.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган бүлектә эшләүченең шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, яисә мөлкәти характердагы хезмәтләр рәвешендә яисә өченче затлар өчен керемнәрнең хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүлек хезмәткәре тарафыннан алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.1.3. Бүлек җитәкчесе эш бирүчегә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

6.1.4. Бүлек хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында бүлек җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш. Бүлек башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе бүлек начальнигы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru.

Совет председателе,
Район башлыгы Р.Г. Кәлимуллин